КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 45

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Минем субсидияләр» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 ел, 30 декабрь, 1769 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында»;

1 пунктның икенче абзацында «дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карарга теркәлгән «Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне расларга.»;

әлеге карарга «Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләрне алучыларны сайлап алу башкарыла торган дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2024 ел, 28 ноябрь, 1074 нче карарына, 1 пунктның икенче абзацындагы «дәүләт мәгълүмат системасы» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Тәрҗемәче: А.М.Сәгыйтова

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 декабрь, 1769 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 30 гыйнвар, 45 нче
карары редакциясендә)

«Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы
дәүләт мәгълүмат системасы турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Минем субсидияләр» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – Система) эшләвен оештыру тәртибен билгели.

мәгълүмат системасы – мәгълүматлар базаларындагы мәгълүмат һәм аны эшкәртүне тәэмин итә торган мәгълүмат технологияләре һәм техник чаралар җыелмасы;

## II. Система эшчәнлегенең максаты

2.1. Система Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясындагы 1 һәм 7 пунктлары, 78 1 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары, шулай ук Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан (Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан) бирелә торган субсидияләрне (субсидияләр формасында грантларны кертеп) (алга таба – ярдәм чаралары) бирү барышларын цифрлаштыру максаты белән эшли.

## III. Система белән мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар

3.1. Система белән мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар:

Системаның дәүләт заказчысы һәм операторы – «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

мәгълүматка ия булучы – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;

функциональ файдаланучы – Татарстан Республикасы бюджеты (Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетлары) акчасы белән баш эш итүче Татарстан Республикасы дәүләт органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы, шулай ук Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) нигезендә ярдәм чаралары

күрсәтү өчен вәкаләт бирелгән оешмалар;

мөрәҗәгать итүчеләр – Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) нигезендә ярдәм чаралары күрсәтелүгә дәгъва итүчеюридик затлар, индивидуаль эшкуарлар, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затлар.

3.2. Системаның дәүләт заказчысы һәм операторы:

Системаны һәм аның элементларын модификацияләү (модернизацияләү), аларның эшкә сәләтен (эшләвен) тәэмин итү максатларында һәм Системаның һәм аның элементларының эшләвенә бәйле башка максатларда товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләреннән файдалануның махсус хокукын һәм (яки) файдалану хокукын сатып алуны гамәлгә ашыра;

Системаны эксплуатацияләү, шул исәптән аның мәгълүматлар базаларындагы мәгълүматны эшкәртү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

Системада эшкәртелә торган мәгълүматны саклау һәм аны булдыру, үстерү һәм техник яктан тәэмин итү чараларын үткәрүне тәэмин итә;

Системаның, шул исәптән система эшләве өчен кирәкле программа тәэминатының, сервер, челтәр һәм башка җиһазның эшләвен тәэмин итә;

Системадагы мәгълүматны саклау өчен кирәкле программа тәэминатының һәм җиһазның эшләвен тәэмин итә;

Система белән мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлегенә һәм белешмәләр алу һәм бирү тәртибенә карата таләпләрне билгели;

функциональ файдаланучыларга һәм мөрәҗәгать итүчеләргә Системадан файдалау мөмкинлеге бирә;

мәгълүматны саклау өлкәсендә норматив хокукый актлар таләпләре нигезендә Системадагы мәгълүматны саклауны тәэмин итә.

3.3. Мәгълүматка ия булучы:

Системадагы мәгълүматны саклауга карата таләпләр булдыруны тәэмин итә;

Система мәгълүматын саклау системасын эшләүне һәм гамәлгә кертүне оештыра;

Системадагы мәгълүматны саклау чараларын кабул итүне оештыра;

әгәр норматив хокукый актларда чикләү бурычы билгеләнгән булса, Системадагы мәгълүматтан файдалануны чикләүне оештыра;

мөрәҗәгать итүчеләрне сайлап алу буенча Системаның функциональлеген гамәлгә ашыруны килештерә.

3.4. Функциональ файдаланучы:

Системада эшләү өчен боерык бирү характерындагы акт белән хезмәткәрләрне (алга таба – җаваплы хезмәткәрләр) билгели һәм билгеләп куя;

җаваплы хезмәткәрләр белән Системада эшләү тәртибе, мәгълүматны саклау кагыйдәләре һәм чаралары белән танышу күздә тотылган инструктажны үткәрә;

Системадан файдаланып, ярдәм чаралары күрсәтүне тәэмин итә;

Системага кертелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм актуальлеген тәэмин итә;

Системада эшләгәндә законнар таләпләре нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүне тәэмин итә;

автоматлаштырылган эш урыннарында мәгълүматның сакланышын тәэмин итә.

## IV. Система функцияләре

4.1. Мөрәҗәгать итүчеләр өчен Системаның төп функцияләре:

Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге ярдәм чаралары белән танышу;

мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүмат нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге ярдәм чараларын автомат рәвештә алдан сайлап алу;

Системадан файдаланып, ярдәм чаралары күрсәтү турында гариза бирү;

Системадан файдалануга юнәлдерелгән ярдәм чаралары күрсәтү турында гариза статусын күзәтеп тору;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^5$ статьясындагы 5 пунктының өченче абзацында каралган очракларда, Системадан «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасына белешмәләрне автомат рәвештә тапшыру;

мөрәҗәгать итүчеләрнең шәхси кабинетын алып бару.

4.2. Функциональ файдаланучылар өчен Системаның төп функцияләре:

ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризалар һәм аларга теркәлгән документлар реестрын алып бару, аларны карау өчен мөмкинлек булдыру;

ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризаны карап тикшерү, аңа карата җаваплы хезмәткәр карар кабул итү һәм комментарий күрсәтү өчен мөмкинлек булдыру;

Системадан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә өстәмә мәгълүмат бирү турында рәсми сорау җибәрү;

ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризалар кабул ителә башлау датасын билгеләү;

хисаплар төзү.

4.3. Системаның функциональлеге дәүләт заказчысы һәм Система операторы тарафыннан үзгәртелергә мөмкин.

## V. Системаның составы

5.1. Система түбәндәге функциональ модульләрдән тора:

«Мөрәҗәгать итүче» – мөрәҗәгать итүчеләргә Системаның функциональлеген файдалану өчен билгеләнгән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://subsidiya.tatarstan.ru/ адресы буенча урнашкан сайтны һәм «iOS» һәм «Android» операцион системалары өчен мобиль кушымталарны үз эченә ала;

«Башкаручы» – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://arm–subsidiya.tatarstan.ru// адресы буенча урнашкан сайт ярдәмендә функциональ файдаланучыларга Системадан файдалану өчен билгеләнгән;

«Администратор» – Система аша ярдәм чаралары күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итеп була торган әлеге чаралар турында мәгълүмат булдыру һәм аңа төзәтмәләр кертү, шул исәптән ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризалар формаларын, белешмәлекләр һәм алгоритмнар булдыру һәм аларга төзәтмәләр кертү

өчен билгеләнгән.

5.2. Системаның функциональ модульләре составы Системаның дәүләт заказчысы һәм операторы тарафыннан билгеләнә.

## VI. Системадан файдалану мөмкинлеге

6.1. Системадан файдалану мөмкинлеге кабул ителгән рольләр, бурычларны бүлү һәм, аутентификация һәм авторизация чараларын кулланып, вәкаләтләрне минимизацияләү принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## VII. Системаның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү

7.1. Системаның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары һәм һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

7.2. Системадагы мәгълүматны саклау мәгълүматның оештыру һәм техник саклау чараларын куллану, шулай ук Системаны эксплуатацияләүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә.

7.3. Система Техник һәм экспорт контроле федераль хезмәтенең «Дәүләт мәгълүмат системаларындагы дәүләт серен тәшкил итмәгән мәгълүматны яклау турындагы таләпләрне раслау турында» 2013 елның 11 февралендәге 17 номерлы боерыгы нигезендә аттестацияләргә тиеш.

7.4. Система белән мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар Системаны аттестацияләү таләпләре нигезендә Система белән эшләгәндә автоматлаштырылган эш урыннарында мәгълүматны саклауны тәэмин итәргә тиеш. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм саклауга карата мәгълүмати иминлек буенча таләпләрне бозган өчен Система белән мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар законнарда каралган тәртиптә җавап бирә.